**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«19» апрель 2016 ел Боерган авылы № 5

2015 елда Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү турында

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының «2015 елда Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» карар проекты турында фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатында, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегендә халык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елда Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында 2016 елның 20 апреленнән дә соңга калмыйча урнаштырырга.
3. Билгеләргә:
3.1 Халык тыңлауларын үткәрү вакытын - 26 апрель 2016 ел в 10.00 сәг.;
3.2 Үткәрү срогы – 1 көн;
3.3 Үткәрү урыны - ТР,Тукай р-ны, Боерган авылы, Мирная ур., 64.
3.4 тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә м чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга гариза бирелергәөмкин булган адрес: ТР, Тукай р-ны, Боерган авылы, Мирная ур., 64
3.5 гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү срогы – 2016 елның 25 апреленә кадәр. (тел. 37-78-2).
4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге башкарма комитетына карар проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы З.М. Камилҗанов